СОВЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная , д. 2а, д.НижниеАты,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 2 йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

**Тел. (84366)507-35, факс (84366)507-35. E-mail: Sat .Ars@tatar.ru**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**

**Урта Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**31 октябрь 2019 ел** **№5**

**Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Урта Аты авылында гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Урта Аты авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1.Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Урта Аты авылында , Күпер урамы, 4а йорт адресы буенча гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2019 елның 15 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Урта Аты авылында ,Тау өсте урамы, 18 нче йорт адресы буенча гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2019 елның 16 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.Торак пункта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап:Күпер урамында яшәүчеләр

2нче этап:Тау өсте урамында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Урта Аты авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә,түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы

студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзарасалым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Урта Аты авылында урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру.
- Урта Аты авылындагы су колонкасын төзекләндерү өчен , материаллар сатып алу һәм будкасын ремонтлау;
- Күпер урамында юл-урам челтәренең ремонтлау;
- Тау өсте урамына юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш түшәү

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

| “ӘЙЕ” | “КАРШЫ” |
|---|---|

5. Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Урта авылында гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Түбән Аты авылы, Үзәк урам, 37 йорт; ТР, Арча районы, Урта Аты авылы, Күпер урамы, 39 йорт адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Аты авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Батталова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «СРЕДНЕАТЫНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» * СОВЕТ СРЕДНЕАТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609002912